Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районының
Олы Талкыш авыл җирлеге Советы
Карары

№5/2 2020 елның 30 декабре

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Олы Талкыш авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Олы Талкыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге милкендәге муниципаль мөлкәт исемлеген кече һәм урта эшкуарлык субъектларына биләүгә һәм (яисә) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән муниципаль мөлкәт исемлеген булдыру, алып бару һәм бастырып чыгару тәртибен раслау турында» 2019 елның 5 июнендәге 36/3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Чистай шәһәр прокуратурасының 2020 елның 11 декабрендәге 02-08-02-2020 номерлы протестын карап чыкканнан соң, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Федераль законы һәм «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Федераль законына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 1 һәм 2 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 08 июнендәге 169-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Олы Талкыш авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Олы Талкыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге милкендәге муниципаль мөлкәт исемлеген булдыру, алып бару һәм бастырып чыгару тәртибен раслау турында» 2019 елның 05 июнендәге 36/3 номерлы карарына кече һәм урта эшкуарлык субъектларына биләүгә һәм (яисә) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

исемендә «кече һәм урта эшкуарлык субъектларына» сүзләреннән соң «, индивидуаль эшкуарлар булмаган һәм махсус салым режимын кулланучы физик затларга» сүзләрен өстәргә.;

1 пунктта:

«кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче» сүзләреннән соң «, индивидуаль эшкуарлар булмаган һәм махсус салым режимын кулланучы физик затларга» сүзләрен өстәргә.;

Карарның 1 нче кушымтасында:

исемендә, 1.1, 1.4, 2.4 пунктларында «кече һәм урта эшкуарлык субъектларын яклау инфраструктурасын барлыкка китерүче» сүзләреннән соң «, индивидуаль эшкуарлар булмаган һәм махсус салым режимын кулланучы физик затларга» сүзләрен өстәргә.

3. Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләрне күпләп җыелган урыннарда, игълан итү стендларында һәм такталарында элү юлы белән игълан

итәргә, шулай ук Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (http://chistopol.tatarstan.ru/) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Олы Талкыш авыл җирлеге Советының законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Олы Талкыш авыл җирлеге
башлыгы Э.Б.Ильин